РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

САБИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

СОВЕТ САТЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

422070, Республика Татарстан, Сабинский район,
С.Сатышево, ул. Ленина, 17Б
тел. (8262) 2-24-16

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

САТЫШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422070, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Сатышавылы, Ленин урамы, 17Б йорт
тел. (8262) 2-24-16

e-mail: Sat.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
20.01.2023

КАРАР
№1

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителгән 10.03.2016 ел, №16 « Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлегендә муниципаль вазыйфа биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфа биләүчеләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырылуы турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Район прокуратурасының 11.01.2023 ел, №02-08-02/8-15-20920031 протесты нигезендә Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителгән 10.03.2016 ел, №16 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфа биләүчеләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырылуы турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфа биләүчеләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырылуы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Сатыш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфа биләүчеләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырылуы турында Нигезләмәнең 8нче пунктындагы 3нче п.п. түбәндәгечә бәян итәргә:

3) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (катнашу өлешләре,

оешмаларның устав (туплау) капиталында пайлар), цифрлы финанс активлары, хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алу буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр хисап чорына кадәрге өч ел эчендә әлеге гражданның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кереме һәм акча алу чыганаклары турында, алар хисабына эшләнелгән әлеге алыш-бирешләрдән артып китсә.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/ satish адресы буенча урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольгә алуны үз өстемдә калдырам.

Сатыш авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Шафигуллин